РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«7» апреля 2026 ел г. Альметьевск № 28

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Башлыгының
«Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы муниципаль
вазыйфаларын биләүче затларның,
Әлмәт муниципаль районы муниципаль
хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә
әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм
мөлкәти характердагы йөкләмәләре
турында белешмәләрне Әлмәт муниципаль
районының рәсми сайтында урнаштыру
һәм әлеге белешмәләрне бастырып
чыгару өчен массакүләм мәгълүмат
чараларына бирү тәртибе турында
нигезләмәне раслау хакында»
2011 елның 17 мартындагы 18 номерлы
карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында»Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2025 елның 7 маендагы 362 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Әлмәт муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе

турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 17 мартындагы 18 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны аппарат җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Е. Әфләтуновага йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы Г.М. Хәбутдинова